| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Кучуковского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Көчек авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.09.2026 Түбән Көчек авылы № 2

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен туры китерү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 09.09.2026 № 15-1 карары, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге һәм аның составына керүче аерым муниципаль берәмлекләр чикләре турында» карары, «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Көчек авыл җирлеге Советының «Әгерҗе муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеген оештыру һәм гавами тыңлауларны оештыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 13 августындагы 37-3 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән Татарстан Республикасы чикләренә туры китерү мәсьәләсе буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 2026 елның 25 сентябренә 09.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Түбән Көчек авылы, Ленин урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан Көчек авыл мәдәният йорты бинасында гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларда тикшерелә торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр 2026 елның 22 сентябренә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Түбән Көчек ав., Ленин ур., 12 йорт.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталы составында Әгерҗе муниципаль районы рәсми сайтына урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru , шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль

районының Көчек авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Түбән Көчек авылы, Ленин ур., 12 йорт адресы буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башлык А.Р. Төхфәтуллина